Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

№4 (22)

Май-июнь, 2017 нче ел



**Мөслим гимназиясенең чираттагы 13 нче чыгарылыш укучыларына багышланган махсус сан**



БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” VI Республика конкурсы җиңүчесе - 2009.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – 446 укучы, 48 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

## ХӘЕРЛЕ ЮЛ, ЯШЬ ДУСЛАР!

Кошлар да, канатларын ныгыткач, балаларын читкә очыра. Гимназия үнөченче мәртәбә укучыларын яңа тормыш юлына озата. Быел Мөслим гимназиясен 21 егет һәм кыз тәмамлый. Алар арасында химия, биология, экология, татар теле һәм әдәбияты, математика, физика, тарих, җәмгыять, рус теле һәм әдәбияты, технология һәм физкультура фәннәре буенча район олимпиадасы җиңүчеләре, республика призерлары бар.

Быелгы чыгарылыш укучылар гимназия тарихында иң оешкан, иң актив, иң музыкаль сыйныф буларак язылып кала.

Кадерле укучыларыбыз! Сезнең белән бергә үткәргән кызыклы кичәләр, спорт бәйгеләре, күңелле походлар, чаңгы ярышлары, “Аҗаган” хәрби уеннары - барысы-барысы якты мизгел булып хәтерләрдә сакланыр.

Гимназия стеналарында алган белемнәр, укытучыларыгыз, ата-аналарыгыз биргән тәрбиягез сезгә тормыш юлында маяк булсын! Мәктәп чоры дуслыгы



озак еллар дәвам итсен!

Киләчәк сезнең кулда!

Хәерле юл сезгә, укучылар!

***Хөрмәт белән,***
***Азат Фәритович***

## БӘХЕТ ИЛЕНӘ АТЛАГЫЗ!

*Мәктәп еллары!*
*Нинди гүзәл көннәр!*

Тупланганнар аңа барысы да: бетмәс-төкәнмәс шатлык-борчулар, елмаюлы йөзләр, шау-гөр килеп узган кичәләр, шаян җырлар, керсез хыяллар...

Укучыларым, 7 ел сезнең белән бергә үткән гомер “әкият” илен хәтерләтеп артты калды. Сез бүген зур тормышка, олы юлга беренче адымыгызны ясыйсыз.

Кадерле балалар, сез мәктәп тормышында гына актив булып калмыйча, район һәм республика күләмендә уздырылган чараларда да теләп катнаштыгыз, матур үрләр яуладыгыз, гимназиябезнең горурлыгы булдыгыз!

Ә бу үрләрне сез бары тик фидакарь укытучыларыбыз ярдәме белән генә яулый алдыгыз. Кайда гына булсагыз да, үзегезгә белем биргән укытучыларны онытмасагыз иде.

Тормыштагы һәртөрле авырлыкларны җиңәргә ярдәм итүче, шатлык-борчуларыгызны бүлешүче иң якын кешеләрегез бар. Алар – сезнең әти-әниләрегез.

Хөрмәтле әти-әниләр, сездә һәрчак аңлау һәм ныклы терәк таптым. Рәхмәт сезгә барысы өчен дә. Балаларыгызның игелеген күреп бәхетле тормышта яшәгез.

Укучыларым, имтиханнарны уңышлы тапшырып, кулыгызга өлгергәнлек аттестаты алдыгыз. Алда сезне зур тормыш сынаулары көтә. Мин ышанам: сез юлыгызда булган киртәләрне акыл, намус белән үтәрсез, максатларыгызга барып җитәрсез. Гимназиядә алган



белемнәрегез сезне һәрчак алга әйдәп торсын. Эшләрегез һәрчак уң булсын! Мөслимебез үсешенә өлеш кертердәй лаеклы алмаш булыгыз!

Бәхет иленә атлагыз!

Ак юллар!

***Сезне яратып,***
***Азилә Рамиловна***

# К Ы Ң Г Ы Р А У Л Ы   М Ә К Т Ә П   Е Л Л А Р Ы



***Әгълиуллина Язилә***
Шушы тырышлыгы белән
Барса әгәр Язилә,
Доктор булып әйләнеп
Кайтыр әле Мөслимгә!

***Динара Бәдертдинова***
Нинди эшкә тотынса да,
Максатына ирешә.
Динара, бул син бизнес-леди
Сиңа бар да килешә!



***Регина Шәйгәрданова***
Бар яктан да унган-булган,
Һәрвакыт шат күңелле.
Сәхнәләрдә балкып тора -
Регинабыз түгелме?!



***Талия Җиһангирова***
Талиягә барырсыз сез
Авыртканда тешегез.
Стоматологлар ягында
Булыр ул үз кешебез!

***Гөльяз Хәлимова***
Яңадан-яңа ачышлар
Көтәбез синнән, Гөльяз!
Бик акыллы, бик белемле,
Ә күңелең һәрчак яз!

***Илнур Шәймөхәмәтов***
Һичбер шик юк:
Синнән, Илнур,
Яхшы доктор чыгачак!
Сиңа кирәргә чиратта
Бик күп кеше торачак!



***Риназ Әюпов***
Үтә дә җаваплы карый
Риназ һәрбер эшенә.
Ышанычлы, игътибарлы
Дус ул һәммә кешегә!

***Айгөл Минһаҗева***
Айгөлебез – кабатланмас!
Зәвыклы, тәрбияле!
Аның кебек кем булдыра,
Тырышып кара, яле?!



***Альбина Исламова***
Альбинабыз киң күңелле,
Инша язу остасы.
Тырышлыгың, уңганлыгың өчен
Килә сине мактасы.

***Руслан Петров***
Төрле яклап булган Руслан,
Бер җире юк килмәгән.
Ирешелгәндә туктама син,
Калмасын син белмәгән!



# КЫҢГЫРАУЛЫ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫ



***Зәйнәп Хөснетдинова***
Зәйнәбебез – гади, тыйнак,
Үтә чибәр кызыбыз.
Тырышлыгы бик зур аның
Булыр бер йолдызыбыз.

***Фирзәр Исламов***
Фирзәрнең яхшы яклары
Безне үзенә тарта.
Елмаюы белән балкып
Борчуларны тарата.



***Регина Имамова***
Бик тырыш кыз Регинабыз,
Киләчәктә сынатмас.
Утта янмас, суда батмас –
Беркайда да югалмас!



***Лиана Харисова***
Лианабыз – май кояшы,
Күңеле – саба җиле!
Киләчәктә көтсен сине
Бәхет, шатлыклар иле!

***Эльвина Мирзасалихова***
Офиска яхшы хезмәткәр
Кирәк булса - белегез:
Эльвинабыз менә дигән!
Килегез дә күрегез!

***Нурислам Сәлимгәрәев***
Нурислам – иң асыл егет,
Креатив та ул үзе.
Ышанабыз Нурисламга,
Күрсәтә белер үзен!

***Алмаз Вәлиев***
Туп-турысын әйтеп бирә
Алмаз карап күзеңә.
Прокурор я юрист булса
Бик килешер үзеңә!



***Тимур Салахов***
Тимур – физик, энергетик.
Техник иҗат ярата.
Киң күңеле белән һәрчак
Ул үзенә карата.

***Динара Зарипова***
Физиканы үз иткән кыз –
Динара ул – белегез!
Фәнни ачыш дөньясында
Мөслим кызын күрербез.



***Айгөл Мөхәмәтханова***
Чын күңеленнән елмаеп
Тора бит ул, күрегез!
Инглиз телен һәммәгез дә
Айгөл кебек белегез!

***Софья Симченко***
Синең белән бик күңелле,
Син, Софья, кояш кебек.
Үзең сыман һәрвакытта
Тормышың торсын көлеп!



# ФОТОСУРӘТЛӘРДӘ КАЛГАН ЕЛЛАР














11 ел уку дәвамында 12506 дәрес укыдык,
25012 кыңгырау шалтыравын ишеттек, 152 дәреслекне укып чыктык

ТЫЛСЫМ+

Июнь , 2017 нче ел

*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мухаметханова Айгөл,
**Корреспондентлар:** Мәгъдәнова Ләйсән, Фәрхетдинова Айгөл, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym